Югары Ырга авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

КАРАР № 14

Югары Ырга ав. 2016 елның 3 октябре

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 пунктының «в», Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Югары Ырга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы белән берлектә түбәндәге сораулар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итәргә:

“2016 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- Югары Ырга авылы зиратын койма белән әйләндереп алу
- Яңа Ырга авылында юлларны ремонтлау
-Югары Ырга, Яңа Ырга авылында һәм авылда юлларны кардан чистарту
- Югары Ырга, Яңа Ырга авылында урам читләреннән чүп үләннәре чабу;

ЭЙЕ ЮК

1. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 йорт; Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

2. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Багаутдинов